| Республика Татарстан<br>Глава Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Югары<br>Чыршылы авыл җирлеге<br>башлыгы |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 № 7

2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартында “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Югары Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2025 елның 11 ноябрендә 09.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча урнашкан Усай авылы ФАП бинасында билгеләргә: ТР, Сарман муниципаль районы, Усай торак пункты, Азин урамы, 11а йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Усай торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча машина йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү));

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): трактор тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, Усай торак пунктында запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу).

3) Усай торак пунктындагы Азин урамы буенча су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү));

4) Усай торак пунктында урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Сарман муниципаль районы Югары Чыршыды авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 30.11.2025 ел, № 4 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гилева